РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

14 март 2025 ел №3

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Ядегәр авыл җирлеге советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Ядегәр авыл җирлеге Советы Карары проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. Ядегәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча, Ядегәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»28.01.2020 ел, №3 карары нигезендә гавами тыңлаулар үткәрергә. ".

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Ядегәр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча

кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Фәйзуллин Айдар Нәҗип улы - комиссия рәисе;

Әминов Илгиз Госман улы-комиссия әгъзасы;

Леонтьев Алексей Иванович-комиссия члены.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлауларны уздыру датасы – 07.04.2025 ел.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты - 18.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны-Ядегәр авыл мәдәният йорты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Ядегәр авылы, Ленин ур., 21а йорт.

6. Эшче төркемгә гавами тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге Советы утырышы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: httrs://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән http://kukmor.tatar.ru

Җирлек башлыгы: ОГРН 1021607752836 ИНН 1623001639 А.Н.Фәйзуллин

Ядегәр авыл җирлеге Советының
2025 елның 14 мартында кабул ителгән
3 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Ядегәр авыл җирлеге Советы

КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәравыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Ядегәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек)».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: А.Н.Фәйзуллин

Ядегәр авыл җирлеге Советының
2025 елның 14 мартында кабул ителгән
3 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Ядегәр авыл җирлеге Советы Карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында " карар проектына тәкъдимнәр Ядегәр авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Кукмара районы, Ядегәр авылы, Ленин ур., 28а йорт, яисә (84364) 35-5-88 факсы буенча язма рәвештә кушымтада бирелә торган үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| Тәртип номеры | Статья, пункт, подпункт | Карарның проект тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәләрне искә алып проектның тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр карар игълан ителгән көннән алып бер ай эчендә эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Кукмара районы, Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт (конвертта "Устав турында фикер алышу" яисә "гавами тыңлаулар" тамгасы белән), шулай ук (84364) 35-5-88 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Ядегер авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл жирлеге башлыгы урынбасарына тапшырыла.

Җирлек башлыгы: А.Н.Фәйзуллин